Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районың
Хайбулдино авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2024 елның 19 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының
“Чуваш Чүпрәле авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Хайбулдино
торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының “Чуваш Чүпрәле авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Хәйбулдин торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2024 елның 19 ноябре Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуваш-Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуваш Чүпрәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә, Чуваш-Чүпрәле авыл җирлеге Советының 14.10.2019 № 46/1 карары белән расланган Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, хисап комиссиясе мәгълүматлары нигезендә 2024 елның 19 ноябрендә тавыш бирү нәтиҗәләре турында 2024 елның 19 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә төзелде, аның буенча:

Тавыш бирү тәмамланган вакытта гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 69 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 39, бу торак пункт территориясендә гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә кертелгән гражданнар җыенында катнашучыларның 56,52 процентын тәшкил итә.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленгән:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 39 кеше тавыш бирә, бу тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучыларның 100% тәшкил итә; «каршы» позициясе өчен 0 тавыш бирә.
Бу карар нигезендә:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Чуаш-Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Хәйбулдин торак пунктында гражданнар җыены 2024 елның 19 ноябрендә узган дип танылсын, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә.
2. “Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Чуваш-Чүпрәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту” дигән карар кабул ителгән дип санарга.

3. 2025 елда Чүпрәле муниципаль районы Чуваш-Чүпрәле авыл җирлегенең Хәйбулдин торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту

4. Салым түләүдән азат итү:

1) 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар;2) инвалид балаларның ата-аналары (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр), тулы Дәүләт тәэмин итүендә булган балалардан тыш;3) махсус хәрби операциядә катнашучылар;

4) махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзалары (тормыш иптәше (хатыны), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм башка эшкә сәләтсез тәрбияләнүчеләр белән бергә яшиләр), шул исәптән махсус хәрби операция барышында һәлак булганнар, хәбәрсез югалганнар;

5) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында»2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указына ярашлы рәвештә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар;

6) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаилә әгъзалары (тормыш иптәше (хатыны), балигъ булган балалар, ата-аналар һәм башка эшкә сәләтсез тәрбияләнүчеләр), шул исәптән махсус хәрби операция барышында һәлак булганнар, хәбәрсез югалганнар.

5. Әлеге карарны Хәйбулдин авылы, Клуб урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чуваш-Чүпрәле Башлыгы
авыл җирлеге,
рәислек итүче
гражданнар җыенында: В. В. Землемеров